РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№36 1 август, 2018 ел

**Түбән Кама шәһәрендә Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33нче маддәләре, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, күчемсез милеккә ия затларның һәм күчемсез милек объектларын сатып алырга, алардан файдаланырга теләүчеләрнең законлы мәнфәгатьләрен һәм хокукларын тәэмин итү максатыннан, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 декабре 20нче номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәрендә Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре картографик материалларына үзгәрешләр кертергә, кушымтага таянып.
2. Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 декабре 20нче номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәрендә Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең текст өлешендәге 36нчы маддәсенә үзгәрешләр кертергә, «Д-1. Эшлекле, җәмәгать, коммерция билгеләнешендәге зона» территориаль зонасының төп төрләре исемлеген "агросәнәгать парклары" төре белән тулыландырырга.
3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эш бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасы үсеше буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

**Кушымта**

Түбән Кама шәһәр Советының


2018 елның 1 августында кабул ителгән

36нчы номерлы карарына

Правила землепользования и застройки

**г.НИЖНЕКАМСК КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ ТЕРРИТОРИИ**

Выкопировка. Редакция 2017 года




Выкопировка. Внесение изменений




46нчы номерлы микрорайон территориаль зонасы Ж-2 «Азкатлы торак йортлар төзү зонасы»ннан Ж-1 «Шәхси торак йортлар төзү зонасы»на күчерелә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
урынбасары Э.Р. Долотказина